ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

## Татарстан Республикасының азык-төлек куркынычсызлыгы турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2017 елның 22 июнендә
кабул ителде

### 1 статья. Әлеге Законның җайга салу предметы

Әлеге Закон Татарстан Республикасының азык-төлек куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга сала.

### 2 статья. Татарстан Республикасының азык-төлек куркынычсызлыгын тәэмин итүнең хокукый нигезе

Татарстан Республикасының азык-төлек куркынычсызлыгын тәэмин итүнең хокукый нигезен Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары тәшкил итә.

### 3 статья. Төп төшенчәләр

Әлеге Законның максатлары өчен түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

1) Татарстан Республикасының азык-төлек куркынычсызлыгы – Татарстан Республикасы икътисадының Татарстан Республикасының азык-төлек белән тәэмин ителешенә ирешелә торган, техник җайга салу турында, халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында, азык-төлек продуктларының сыйфаты һәм куркынычсызлыгы турында законнар таләпләренә туры килә торган азык-төлек продуктларын Татарстан Республикасында яшәүче һәр кешегә азык-төлек продуктларын куллануның актив һәм сәламәт тормыш рәвеше алып бару өчен кирәкле билгеләнгән рациональ нормаларыннан ким булмаган күләмнәрдә физик һәм икътисадый алу мөмкинлеге гарантияләнә торган торышы;

2) Татарстан Республикасының азык-төлек белән тәэмин ителеше – Татарстан Республикасы халкының азык-төлек продуктларына булган ихтыяҗын Татарстан

Республикасы азык-төлек резервын формалаштыру, Татарстан Республикасы территориясендә авыл хуҗалыгы продукциясенең, чималның һәм азык-төлекнең төп төрләрен Татарстан Республикасы азык-төлек базарының тиешле төрдәге товар ресурсларының гомуми күләмендә (күчеп баручы запасларны да исәпкә алып) аларның чагыштырма авырлыгының әлеге Законда билгеләнгән чик күрсәткечләреннән ким булмаган күләмдә җитештерү, шулай ук үз эшчәнлекләрен Татарстан Республикасы территориясендә алып бара торган оешмаларның җитештерү белән тәэмин ителмәгән күләмнәрдә азык-төлек продуктларын сатып алу юлы белән канәгатьләндерелүе;

3) Татарстан Республикасының азык-төлек куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә вәкаләтле орган (алга таба шулай ук – вәкаләтле орган) – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан Татарстан Республикасының азык-төлек куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә функцияләрне гамәлгә ашыруга вәкаләтләр бирелгән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы;

4) азык-төлек продуктларын куллануның рациональ нормалары – азык-төлек продуктларының заманча дөрес туклану таләпләренә җавап бирә торган күләмнәрдәге һәм нисбәтләрдәге җыелмасы рәвешендә тәкъдим ителә торган туклану рационы;

5) азык-төлек продуктларын икътисадый алу мөмкинлеге – азык-төлек продуктларын билгеләнгән бәяләрдә, азык-төлек продуктларын куллануның билгеләнгән рациональ нормаларыннан ким булмаган күләмнәрдә һәм ассортиментта, халыкның тиешле керемнәр дәрәҗәсе белән тәэмин ителгән сатып алу мөмкинлеге;

6) азык-төлек продуктларын физик алу мөмкинлеге – товар үткәрү инфраструктурасының халыкның азык-төлек продуктларын куллануның билгеләнгән рациональ нормаларыннан ким булмаган күләмнәрдә һәм ассортиментта азык-төлек продуктлары алу яисә туклануны оештыру мөмкинлеге тәэмин ителә торган үсеш дәрәҗәсе;

7) Татарстан Республикасы азык-төлек резервы – авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлекнең Татарстан Республикасының азык-төлек белән тәэмин ителешенә ирешү өчен Татарстан Республикасы азык-төлек резервы операторлары тарафыннан формалаштырыла торган күләмнәре;

8) Татарстан Республикасы азык-төлек резервы операторлары – вәкаләтле орган тарафыннан билгеләнгән, үз эшчәнлекләрен Татарстан Республикасы территориясендә башкара торган, шәхси һәм җәлеп ителгән акчалар исәбенә Татарстан Республикасы азык-төлек резервын формалаштыручы оешмалар.

4 статья. **Татарстан Республикасының азык-төлек куркынычсызлыгын тәэмин итүнең максаты һәм бурычлары**

1. Татарстан Республикасының азык-төлек куркынычсызлыгын тәэмин итүнең максаты Татарстан Республикасы халкының техник җайга салу турында, халыкның

санитария-эпидемиология иминлеге турында, азык-төлек продуктларының сыйфаты һәм куркынычсызлыгы турында законнар таләпләренә туры килә торган азык-төлек продуктларына булган ихтыяҗларын азык-төлек продуктларын куллануның актив һәм сәламәт тормыш рәвеше өчен кирәк булган билгеләнгән рациональ нормаларыннан ким булмаган күләмнәрдә канәгатьләндерүдән гыйбарәт.

2. Татарстан Республикасының азык-төлек куркынычсызлыгын тәэмин итүнең төп бурычлары түбәндәгеләр:

1) Татарстан Республикасында сыйфатлы һәм куркынычсыз авыл хуҗалыгы продукциясен, чималны һәм азык-төлекне Татарстан Республикасының азык-төлек белән тәэмин ителеш күрсәткечләренә ирешү һәм шуны саклап калу өчен җитәрлек булган күләмдә җитештерүнең тотрыклы үсеше;

2) азык-төлек продуктларын куллануның актив һәм сәламәт тормыш рәвеше өчен кирәкле билгеләнгән рациональ нормаларына туры килә торган күләмнәрдәге һәм ассортименттагы куркынычсыз азык-төлек продуктларының Татарстан Республикасында яшәүче һәр кеше өчен физик һәм икътисадый алу мөмкинлегенә ирешү һәм аны шул дәрәҗәдә тотып тору;

3) Татарстан Республикасының азык-төлек базарын үз вакытында фаразлау, Татарстан Республикасының азык-төлек куркынычсызлыгына янарга мөмкин хәвефләрне бәяләү;

4) Татарстан Республикасының азык-төлек резервын формалаштыру;

5) азык-төлек продуктларының сыйфатын һәм куркынычсызлыгын тәэмин итү.

5 статья. **Татарстан Республикасының азык-төлек куркынычсызлыгын тәэмин итүнең төп принциплары**

Татарстан Республикасының азык-төлек куркынычсызлыгын тәэмин итүнең төп принциплары түбәндәгеләр:

1) базар торышын һәм Татарстан Республикасының азык-төлек куркынычсызлыгын тәэмин итү мәсьәләләрен үтәүгә юнәлдерелгән Татарстан Республикасы дәүләт программаларын үтәүнең төп күрсәткечләрен мониторинглау нигезендә Татарстан Республикасының азык-төлек базарында тотрыклылыкка ирешү;

2) Татарстан Республикасының азык-төлек куркынычсызлыгы торышын мониторинглау максатларында Татарстан Республикасы территориясендә җитештерелгән азык-төлек продуктлары һәм үз эшчәнлекләрен Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыра торган оешмалар тарафыннан сатып алынган азык-төлек продуктлары күләменең исәбен алу;

3) социаль өлкә оешмаларын азык-төлек продуктлары белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру;

4) Татарстан Республикасының азык-төлек базарын җайга салу.

**6 статья. Татарстан Республикасының азык-төлек куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасы Президенты вәкаләтләре**

Татарстан Республикасы Президенты:

1) Татарстан Республикасының азык-төлек куркынычсызлыгын тәэмин итүнең төп юнәлешләрен билгели;

2) Татарстан Республикасының азык-төлек куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башка органнары белән эшчәнлеген координацияләүне тәэмин итә;

3) Россия Федерациясе законнары нигезендә Татарстан Республикасының азык-төлек куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының федераль башкарма хакимият органнары һәм аларның территориаль органнары, җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлеген оештыра;

4) Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә башка вәкаләтләрне башкара.

**7 статья. Татарстан Республикасының азык-төлек куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләре**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы:

1) Татарстан Республикасының азык-төлек куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә законнар белән җайга салуны гамәлгә ашыра;

2) Татарстан Республикасы бюджеты составында Татарстан Республикасының азык-төлек куркынычсызлыгын тәэмин итүгә бәйле чараларны гамәлгә ашыру чыгымнарын раслый;

3) Татарстан Республикасының азык-төлек куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасы законнарын үтәүне һәм гамәлгә ашыруны тикшереп тора;

4) Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә башка вәкаләтләрне башкара.

**8 статья. Татарстан Республикасының азык-төлек куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләре**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты:

1) Татарстан Республикасының азык-төлек куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә бердәм дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруны тәэмин итә;

2) Татарстан Республикасының азык-төлек куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә норматив хокукый актлар чыгара;

3) Татарстан Республикасының азык-төлек куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт программаларын раслый;

4) Татарстан Республикасының азык-төлек куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары эшчәнлеген координацияли;

5) Татарстан Республикасының азык-төлек куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органын билгели;

6) Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә башка вәкаләтләрне башкара.

## 9 статья. **Татарстан Республикасының азык-төлек куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә вәкаләт бирелгән орган вәкаләтләре**

Вәкаләтле орган:

1) Татарстан Республикасының азык-төлек куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башка органнары, федераль башкарма хакимият органнары һәм аларның территориаль органнары, җирле үзидарә органнары белән хезмәттәшлекне гамәлгә ашыра;

2) Татарстан Республикасының азык-төлек резервын формалаштыру тәртибен билгели;

3) Татарстан Республикасы азык-төлек резервы операторларының Татарстан Республикасының азык-төлек резервын формалаштыру буенча эшчәнлеген координацияли;

4) Татарстан Республикасының азык-төлек куркынычсызлыгы торышын мониторинглауны гамәлгә ашыра;

5) сәүдә багланышлары, Татарстан Республикасы территориясендә җитештерелгән азык-төлек продуктлары һәм үз эшчәнлекләрен Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыра торган оешмалар тарафыннан сатып алынган азык-төлек продуктлары күләмнәре турында, шулай ук профильле товар базарларының товар үткәрүчәнлеге хакында җыелма мәгълүматны формалаштыра;

6) Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне башкара.

## 10 статья. **Татарстан Республикасының азык-төлек куркынычсызлыгын тәэмин итү механизмы**

Татарстан Республикасының азык-төлек куркынычсызлыгын тәэмин итү түбәндәгеләрне күздә тота:

1) Татарстан Республикасының азык-төлек куркынычсызлыгы торышын мониторинглауны гамәлгә ашыруны;

2) Татарстан Республикасының азык-төлек куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә чаралар үткәрү каралган Татарстан Республикасы дәүләт программаларын гамәлгә ашыруны;

3) Татарстан Республикасы азык-төлек базарының тиешле төрдәге товар ресурсларының гомуми күләмендә (күчеп баручы запасларны да исәпкә алып) Татарстан Республикасы территориясендә җитештерелгән авыл хуҗалыгы продукциясенең, чималның һәм азык-төлекнең төп төрләре чагыштырма күләме күрсәткечләренең әлеге Законда билгеләнгән чик күрсәткечләрдән ким булмаган күләменә ирешү һәм шуны саклап калу чараларын күрүне;

4) Татарстан Республикасының азык-төлек резервы операторларына Татарстан Республикасының азык-төлек резервын формалаштыруда булышлык күрсәтүне;

5) Татарстан Республикасының азык-төлек куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә башка чаралар үткәрүне.

11 статья. **Татарстан Республикасының азык-төлек куркынычсызлыгы торышы мониторингы**

1. Татарстан Республикасының азык-төлек куркынычсызлыгын бәяләү һәм аңа янарга мөмкин хәвефләрне булдырмый калу максатларында вәкаләтле орган тарафыннан Татарстан Республикасының азык-төлек куркынычсызлыгы торышына түбәндәгеләргә карата мониторинг уздырыла:

1) Татарстан Республикасының азык-төлек куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен кирәкле азык-төлек продуктлары булуга;

2) Татарстан Республикасының азык-төлек куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт программаларының, шартнамәләрнең һәм килешүләрнең үтәлешенә.

2. Татарстан Республикасының азык-төлек куркынычсызлыгы торышына мониторинг үткәрү максатларында вәкаләтле орган Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башка органнары, федераль башкарма хакимият органнары, Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары, азык-төлек продуктларын җитештерүчеләр һәм ташучылар белән мәгълүмат алмашу эшчәнлеген башкара, сәүдә багланышлары, Татарстан Республикасы территориясендә җитештерелгән азык-төлек продуктлары һәм үз эшчәнлекләрен Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыра торган оешмалар тарафыннан сатып алынган азык-төлек продуктлары күләмнәре турында, шулай ук профильле товар базарларының товар үткәрүчәнлеге хакында җыелма мәгълүматны формалаштыра.

12 статья. **Татарстан Республикасының азык-төлек белән тәэмин ителеше күрсәткечләре**

1. Татарстан Республикасының азык-төлек белән тәэмин ителеше торышын бәяләү өчен Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында билгеләнгән критерийлар кулланыла.

2. Татарстан Республикасы азык-төлек базарының тиешле төрдәге товар ресурсларының гомуми күләмендә (күчеп баручы запасларны да исәпкә алып) Татарстан Республикасы территориясендә җитештерелгән авыл хуҗалыгы продукциясенең, чималның һәм азык-төлекнең төп төрләре чагыштырма күләменең Татарстан Республикасының азык-төлек куркынычсызлыгы торышын бәяләү критерие буларак кулланыла торган чик күрсәткечләре түбәндәгечә була:

1) бөртеклеләр – кимендә 95 процент;

2) шикәр – кимендә 80 процент;

3) үсемлек мае – кимендә 80 процент;

4) ит һәм ит продуктлары (иткә күчереп исәпләгәндә) – кимендә 85 процент;

5) сөт һәм сөт продуктлары (сөткә күчереп исәпләгәндә) – кимендә 90 процент;

6) бәрәңге – кимендә 95 процент.

13 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2017 ел, 13 июль
№ 53-ТРЗ